РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава Тумутукского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана, д.62 Б, Азнакаевский район,
с.Тумутук, 423316,
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
башлыгы

Тельман ур., 62 Б йорт, Азнакай районы,
Тымытык авылы, 423316
тел./факс (885592)34-3-42
E-mail: Tumut.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«22»сентябрь 2023 ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставының 15.1 маддәсе нигезендә, Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**карар итте:**

1. 2023 елның 10 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 10 октябрь 2023 ел 10.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Әгер авылы, Совет ур., 27 йорт, Әгер авыл мәдәният йорты залы;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 30 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт;

- сайлау хокукына ия булган Әгер торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Әгер торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез 2024 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Әгер авылында Җәлил, Совет, Тукай урамнарында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

«РИЗА» "КАРШЫ"

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман ур., 62Б йорт, Әгер авылы, Совет ур., 27 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы Э.Х.Гыйләҗева